**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы**
**карары**

12.11. 2023 г. № 4

«Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең Кече Сөнчәле авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы «Сөнчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә КАРАР:

1. 2023 елның 22 ноябрендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы, Кече Сөнчәле авылы, Ленин урамы, 38 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең Кече Сөнчәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләнсен.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:
1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең Кече Сөнчәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының 27.10.2023 елгы карарын гамәлдән чыгару турында.

«Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең Кече Сөнчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,( I төркем инвалидлардан ,Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

Торак пунктлар чикләрендә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:
урам яктырту җайланмасы (урам яктыртуын агымдагы ремонтлау, урам яктырту өчен яктырткычлар сатып алу).
торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт эчендә территорияне чүп үләненнән кисү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).
Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту:
- ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Кече Сөнчәле торак пункты зиратының коймасын буяу, материаллар сатып алу һәм буяу буенча эш)
3. Әлеге карарны Сөнчәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә: http://aksubayevo.tatarstan.ru.һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы И.В. Крайнова

СОВЕТ СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ